**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2019 № 971

2020 елга Кама Тамагы муниципаль районы балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләренең нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын хисаплап чыгару буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау турында» 2010 ел, 5 июль, 545 нче карарының 3 нче пункты нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Уставы, Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга расларга (кушымта итеп бирелә):

2020 елга гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәяләренең нормативлары;

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә.

2. Кама Тамагы муниципаль районының финанс-бюджет палатасына гомуми белем бирү оешмалары укучыларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары нигезендә гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары  М.Х.Хәбибулловага йөкләргә.

Җитәкчесе Р. М. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.11. 2019 елның 971 номерлы
Карары белән расланган

2020 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы моделе исеме | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына туры килгән ставка, бер елга сумнарда | автотранспорт чарасы узган юлның бер километрына ставка, сумнарда |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Башкарма комитетының
07.11.2019 елның 971 номерлы
Карары белән расланган

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда балаларны йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар (алга таба - муниципаль хезмәт) белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели.

1. Общие положения

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының факттагы узышы нигезендә исәпләнә.
1.3.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.
1.4.Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узышы турындагы мәгълүмат автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында эшләнгән автотранспорт чарасының факттагы узышы буларак Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i муниципаль берәмлегенә муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла::

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f_m}$ - m модельле автотранспорт чараларының факттагы йөреше;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативының ставкасы бер километрга, сум

$M_m$ - m моделе автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.